**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә кертелгән карантинны бетерергә:

Алексеевск районы Алексеевск шәһәр тибындагы поселогының Калинин урамы;

Алексеевск районының Левашево авылындагы Совет урамы;

Балык Бистәсе районының Казаклар авылындагы Елга яры урамы;

Саба районының Тимершык авылындагы Комаров урамы;

Саба районының Түбән Шытсу авылындагы Ленин урамы;

Саба районының Корсабаш авылы янындагы «Корсабаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан яшь терлекләр асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

Казан шәһәрендә Көньяк-Сәнәгать урамындагы 7 нче йортта урнашкан «Коламбия» ачык акционер җәмгыятенең мөлкәт комплексы территориясе.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 13 апрелендәге ПУ-381 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 16 июнь
№ ПУ-553

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ